ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧЕЛНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Иске Чаллы ав. КАРАР

«18» ноябрь 2021 ел № 26

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 29.07.2021 ел, № 18 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 29.07.2021 ел, № 18 карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2.1. 1.5 пунктының 2 - 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслы системасын эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 28 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы «Адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына нигезләнеп файдаланыла».»;

2.2. 1.5 пунктының 11 - 17 абзацларын тиешенчә 3 - 9 абзацлар дип санарга;

2.3. 2.6.1 пунктының 8 пунктчасында. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль район башкарма комитеты яисә җирле үзидарә органы " сүзләренә алмаштырырга»;

2.4. 2.6.4 пунктта «башкарма комитетның структур бүлекчәсе тарафыннан» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга».

3. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Захаров